СОВЕТ МАЛОКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.З.Закирова, д.47, с. Малые Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422172

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИРМӘНАВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
З.Закиров ур., 47 нче йорт, Кече Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422172

тел.(факс): (85563) 2-96-17; e-mail: MKir.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Решение

№ 3-25 — 20 сентябрь 2017 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 23.03.2004 № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кече Кирмән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдумны үткәрергә:
««Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**1. Торак пункт чикләрендә су белән тәэмин итү, су чыгару оештыру:**

**- Кече Кирмән торак пунктында су башнясы урнаштыру;**

**- Кече Кирмән, Норма урманчылыгы, Югары Яке, Норма торак пунктларында су башняларын техник яктан җиһазлау өчен җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру**

**2. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:**

**- Кече Кирмән, Норма, Югары Яке, Норма урманчылыгы, Су-Елга торак пунктларында янгын гидранты җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру.**

«ӘЙЕ» «ЮК»

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Аскаровка йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге Советы рәисе /Г.М.Аскаров/